МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 87/о

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«10» 06 2015

**2015 ел өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлауда эш төрләренең үлчәү берәмлегенә карата чик күләмдәге чыгымнар турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре” турында 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы турында нигезләмәне үтәү, социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлау программаларын формалаштыру, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчасын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны контрольдә тотуны тәэмин итү максатында **боерык бирәм**:

1. Кушымта булып килүче 2015 ел өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлауда эш төрләренең үлчәү берәмлегенә карата чик күләмдәге чыгымнарның нормативларын (алга таба – Нормативлар) расларга.

2. Түбәндәгеләрне киңәш итәргә:

Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсенә, капиталь ремонт программасына кертелгән социаль-мәдәни өлкә объектларына капиталь ремонт буенча смета исәп-хисапларына экспертиза ясаганда, Нормативларга таянып эш итәргә;

3. Юридик бүлеккә (Латыйпова Э.Ю.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ РЕГЛАМЕНТА И КОНТРОЛЯ №1

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2015 елның
“10” 06 №87/о
боерыгы белән расланды

**2015 ел өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын капиталь ремонтлауда эш төрләренең үлчәү берәмлегенә карата чик күләмдәге чыгымнарның нормативлары**

| № п/п | Боерык буенча № | Эшләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хакы, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| | **1.** | **Фасадлар** | | |
| | | ***Фасадларны ремонтлау*** | | |
| 1 | 1.1 | Штукатурланмаган фасадны ремонтлау (стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен штукатурлау, буяу) | кв. м | 346 |
| 2 | 1.2 | Алга таба буяп, кирпечтән салынган стеналарның 50% артык өлешен ремонтлап, штукатурланмаган фасадны төзекләндерү | кв. м | 1 112 |
| 3 | 1.3 | Стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен тышлап, штукатурланмаган фасадны буяу | кв. м | 354 |
| 4 | 1.4 | Фасадны җылыткычы булмаган сайдинг белән тышлау | кв. м | 2 159 |
| 5 | 1.5 | Пенополистирол белән җылытып, фасадны сайдинг белән тышлау | кв. м | 2442 |
| 6 | 1.6 | Минералмамык плитәләр белән җылытып, фасадны сайдинг белән тышлау | кв. м | 2809 |
| 7 | 1.7 | Фасадны җылытмыйча, “ФАССТ” тибындагы металл каркаслы ясалма плитәләр белән тышлау | кв. м | 2176 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | 1.8 | Фасадны җылытмыйча, металл каркасы буйлап, керамогранит плитәләр белән тышлау | кв. м | 2410 |
| 9 | 1.9 | Фасадны җылытып, металл каркасы буйлап, керамогранит плитәләр белән тышлау | кв. м | 3186 |
| 10 | 1.10 | Штукатурланган фасадны ремонтлау (стенаның тышка чыгып торган аскы өлешендәге штукатуркасын (100%) һәм стеналарны ремонтлау, буяу, стеналарны ныгыту һ.б.) | кв. м | 648 |
| 11 | 1.11 | Катнаш фасадны ремонтлау (стеналарны һәм стенаның тышка чыгып торган аскы өлешендәге штукатуркасын ремонтлау, буяу) | кв. м | 384 |
| 12 | 1.12 | Панель фасадны ремонтлау (җөйләрне ремонтлау, стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен буяу һ.б.) | кв. м | 942 |
| 13 | 1.13 | “Җылы җөй” тибында панельләр арасындагы җөйләрне ремонтлау | пог. м | 715 |
| | 1.14 | ***Бина тирәли фундаментны судан саклаучы авыш өслекне ремонтлау*** | | |
| 14 | 1.14.1 | Бетоннан ясалган авыш өслекне арматура ярдәмендә ныгыту һәм гидроизоляцияләү | кв. м | 1836 |
| 15 | 1.14.2 | Бетоннан ясалган авыш өслекне, ян-якларына таш урнаштырып, арматура ярдәмендә ныгыту һәм гидроизоляцияләү | кв. м | 2734 |
| 16 | 1.14.3 | Асфальт-бетоннан ясалган авыш өслек | кв. м | 1051 |
| 17 | 1.14.4 | Нигезен ясап, ян-якка ташлар куеп, тротуар плитәсеннән ясалган авыш өслек | кв. м | 2546 |
| | 1.15 | ***Стенаның тышка чыгып торган*** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | *аскы өлешен ремонтлау* | | |
| 18 | 1.15.1 | Стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен керамикалы фасад плитәсе белән тышлау | кв. м | 2263 |
| 19 | 1.15.2 | Стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен, челтәр буйлап штукатурлап, керамикалы фасад плитәсе белән тышлау | кв. м | 2621 |
| 20 | 1.15.3 | Стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен гидрофобизаторлы сыекча белән эшкәртү | кв. м | 76 |
| | | ***Стеналарны ремонтлау*** | | |
| 21 | 1.16 | Стеналарны, 10 мм киңлектә ачылган бер метр ярыкны инъекцияләү ысулы белән, торгызу | м | 6735 |
| 22 | 1.17 | Һава йөрсен өчен җилләткеч рәшәткәләр урнаштыру | данә. | 1309 |
| 23 | 1.18 | Махсус чокырларны ремонтлау (корылманы ремонтлау, штукатурлау, ябулы әвеслек) | кв. м | 3829 |
| 24 | 1.19 | Керү ишеге өстендә профлисттан әвеслек урнаштыру | кв. м | 991 |
| 25 | 1.20 | Фасадны граффитидан саклагыч чаралар белән вандалларга каршы тышлау | кв. м | 142 |
| 26 | 1.21 | Кирпеч стеналарны капиталь ремонтлау (тоташтыргычларны, плитәләрне демонтажлау стеналарны сүтү, кирпечтән өю) | куб. м | 17 668 |
| 27 | 1.22 | Янгын баскычын буяп, алмаштыру | т | 79 218 |
| 28 | 1.23 | Янгын вакытында чыгу ишекләренең өске өлешен ремонтлау | кв. м | 2 283 |
| | **2.** | **Керү төркемнәре, тәрәзәләр, ишекләр** | | |
| | 2.1 | ***Тәрәзәләр*** | | |
| 29 | 2.1.1 | Җылытмыйча, сөзәк җирләрен | кв. м | 6415 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ремонтлап һәм буяп, тәрәзә блогын (пластик) алмаштыру | | |
| 30 | 2.1.2 | Сөзәк җирләрен пенополистиролбетон белән җылытып, ремонтлап һәм буяп, тәрәзә блогын (пластик) алмаштыру | кв. м | 7895 |
| 31 | 2.1.3 | Җылытмыйча, сөзәк урыннарын пластик панельләр белән тышлап, тәрәзә блогын (пластик) алмаштыру | кв. м | 7534 |
| 32 | 2.1.4 | Җылытып, сөзәк урыннарын пластик панельләр белән тышлап, тәрәзә блогын (пластик) алмаштыру | кв. м | 7858 |
| 33 | 2.1.5 | Пенополистиролбетон белән җылытып, тәрәзә уемнарын кирпечтән салу | куб. м | 6103 |
| 34 | 2.1.6 | Тәрәзәнең сөзәк урыннарын ремонтлау (штукатурлау, җылыту, буяу) | кв. м | 1020 |
| | 2.2 | ***Керә торган ишекләр*** | | |
| 35 | 2.2.1 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агачтан ясалган керү ишекләрен җылытылган металл ишекләргә алмаштыру | кв. м | 9226 |
| 36 | 2.2.2 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агачтан ясалган керү ишекләрен янгынга каршы металл ишекләргә алмаштыру | кв.м | 12447 |
| 37 | 2.2.3 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агачтан ясалган керү ишекләрен ПВХ ишекләргә алмаштыру | кв. м | 8380 |
| 38 | 2.2.4 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агачтан ясалган керү ишекләрен алюминий ишекләргә алмаштыру | кв. м | 13191 |
| 39 | 2.2.5 | Алга таба эшкәртеп, керү ишекләре өстендәге стенаны ясау | кв. м | 4036 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | (кирпечтән өю) | | |
| | 2.3 | ***Керү төркемнәре*** | | |
| 40 | 2.3.1 | Керү төркемнәрен ремонтлау (ишекләрне, түбәләрне, тамбур идәннәре өслеген алмаштыру; бусага ишеге өстендәге түбә өлешен алмаштыру, идән, стена өслеген алмаштыру; инвалидлар өчен күгәрми торган корычтан пандус кору һ.б.) | кв. м | 14558 |
| 41 | 2.3.2 | Күгәрми торган корычтан киртәле пандуслар кору | кв. м | 15811 |
| | **3.** | **Түбәләрне ремонтлау** | | |
| 42 | 3.1 | Йомшак түбә (эретелә торган), сутөшергеч, аэраторлар урнаштырып, кирпеч парапетны – кәрнизен сүтеп һәм торгызып, җылытып, пароизоляцияләп, арматура белән тарттырып, гидроизоляцияләп, чыгу будкасын түбәгә алмаштырып һ.б. | өслекнең кв. м | 4591 |
| 43 | 3.2 | Корыч кәгазеннән ясалган тигез түбәне буялган профнастилга алмаштыру (атланмалык системасын ремонтлау, рәшәткәсен алмаштыру чорма тәрәзәсе ясау, су агып төшә торган системаны алмаштыру, җилләткеч каналларын, зонтларны ремонтлау, түбәгә чыга торган ишекләрне алмаштыру, чардак түшәмәсен җылыту һ.б.) | өслекнең кв. м | 3836 |
| 44 | 3.3 | Шифер түбәне профнастилга алмаштыру - цинклanganга, буялганга (атланмалык системасын ремонтлау, рәшәткәне алмаштыру, җилләтү шахталарын, чорма тәрәзәләрен ремонтлау, | өслекнең кв. м | 3471 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | керү уемын алмыштыру, чардак түшәмәсен алмаштыру һ.б.) | | |
| 45 | 3.4 | Түбәгә чыга торган агач будканы кирпечтән ясалганга алмаштыру, конструкциясен алмаштырып | кв. м | 8086 |
| | 3.5 | ***Чардак түшәмәсен җылыту*** | | |
| 46 | 3.5.1 | Чардак түшәмәсен минералмамык плитәләр белән җылыту | кв. м | 2293 |
| 47 | 3.5.2 | Чардак түшәмәсен ППЖ плитәләре белән җылыту | кв. м | 3217 |
| 48 | 3.5.3 | Агачтан ясалган чардак түшәмәсен ППЖ плитәләре белән җылыту (еш кулланыла торган түшәмә урнаштырып һәм янгыннан саклап) | кв. м | 3611 |
| 49 | 3.5.4 | ЦСП белән тигезләп, агачтан ясалган чардак түшәмәсен ППЖ белән җылыту | кв. м | 2835 |
| 50 | 3.5.5 | Чардак түшәмәсен пенополистироль плитәләр белән җылыту | кв. м | 1592 |
| 51 | 3.5.6 | Агачтан ясалган чардак түшәмәсен XSP 35 белән җылыту, ЦСП белән тигезләп | кв. м | 2652 |
| 52 | | Агачтан ясалган чардак түшәмәләрен ремонтлау (балкалар, төпләмә, янгыннан саклау) | кв. м | 2979 |
| | 3.6 | ***Атланмалык системасын ремонтлау*** | | |
| 53 | 3.6.1 | Атланмалык системасын, рәшәткәләрне тулысынча алмаштыру һәм янгыннан саклау | кв. м | 1063 |
| 54 | 3.6.2 | Атланмалык системасын, рәшәткәләрне ремонтлау һәм янгыннан саклау | кв. м | 487 |
| 55 | 3.6.3 | Атланмалык системасын ныгыту, рәшәткәләрне ремонтлау һәм | кв. м | 861 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | янгыннан саклау | | |
| 56 | 3.7 | Су агып төшә торган торбалар (цинкланган) | м | 902 |
| | **4** | **Эчке төзекләндерү эшләре** | | |
| | 4.1 | ***Эчке ишекләр*** | | |
| 57 | 4.1.1 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агач ишекләрне шпонкаланган (имән) ишекләргә алмаштыру | кв. м | 6835 |
| 58 | 4.1.2 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агач ишекләрне “Эконом” агач ишекләренә алмаштыру | кв. м | 4070 |
| 59 | 4.1.3 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агач ишекләрне ламинат белән тышланган агач ишекләргә алмаштыру | кв. м | 4576 |
| 60 | 4.1.4 | Сөзәк урыннарын ремонтлап, агач ишекләрне нараттан ясалган агач ишекләргә алмаштыру | кв. м | 4214 |
| | 4.2 | ***Эчке стеналар*** | | |
| 61 | 4.2.1 | Керамика плитәне алмаштыру | кв. м | 1392 |
| 62 | 4.2.2 | Стена өемен ремонтлап, керамика плитәне алмаштыру | кв. м | 2596 |
| 63 | 4.2.3 | ГКЛ бүлмәләре корып, уемнар корып һәм ясап, керамика плитәне алмаштыру | кв. м | 1813 |
| 64 | 4.2.4 | Штукатурлап, стена өемнәрен ремонтлап, стеналарны буяу | кв. м | 1710 |
| 65 | 4.2.5 | Штукатурлап, стеналарны буяу | кв. м | 658 |
| 66 | 4.2.6 | Хуҗалык биналарындагы стеналарны штукатурлап буяу | кв. м | 428 |
| 67 | 4.2.7 | Алга таба эшкәртеп, стеналарны ГКЛ белән тышлау (шпаклевкалау, буяу) | кв. м | 796 |
| 68 | 4.2.8 | Агачтан ясалган радиатор рәшәткәләрен ГКЛ белән алмаштыру, алга таба эшкәртеп | кв. м | 683 |
| 69 | 4.2.9 | Алга таба эшкәртеп, ГКЛ чуманнар урнаштыру | кв. м | 1125 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 4.3 | ***Бүлемтекләр*** | | |
| 70 | 4.3.1 | Алга таба эшкәртеп, пыяла бүлемтекләрне ГКЛ белән алмаштыру | кв. м | 1422 |
| 71 | 4.3.2 | Алюминий каркаста ПВХдан ясалган сантехника бүлемтекләре урнаштыру | кв. м | 2447 |
| | 4.4 | ***Идәннәр*** | | |
| 72 | 4.4.1 | Нигезен әзерләп, идәннәрне линолеумга алмаштыру (өслеген ремонтлап, җәелә торган идән, өслеге һ.б.) | кв. м | 2105 |
| 73 | 4.4.2 | Идәннәрне керамика, керамогранит плитәгә алмаштыру, нигезен әзерләп (тигезләү, гидроизоляцияләү, өслеге һ.б.) | кв. м | 2890 |
| 74 | 4.4.3 | Нигезен әзерләп, идәннәрне агачка алмаштыру (ДВП алмаштыру, буяу) | кв. м | 1643 |
| 75 | 4.4.4 | Тышламыйча гына, арматуралап, кирпечтән ясалган подийны алмаштыру | куб. м | 12380 |
| 76 | 4.4.5 | Тышламыйча гына, арматуралап, монолит конструкцияләрне (баскычларны һ.б.) алмаштыру | куб. м | 37546 |
| | 4.5 | ***Түшәмнәр*** | | |
| 77 | 4.5.1 | Штукатуркасын алдан ремонтлап, түшәмнәрне буяу | кв. м | 805 |
| 78 | 4.5.2 | Түшәмнәрне пластик панельләр белән кору | кв. м | 726 |
| 79 | 4.5.3 | Алга таба эшкәртеп, ГКЛ түшәмнәре кору | кв. м | 1424 |
| 80 | 4.5.4 | “Армстронг” тибындагы түшәмнәр кору | кв. м | 681 |
| | | ***Башкалар*** | | |
| 81 | 4.6 | Авыл җирлеге өчен янкорма рәвешендә кирпечтән санузел кору (искесе урынына) (фундаментлар, | кв. м | 37568 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | стеналар, идәннәр, түшәмнәр, түбә, уемнар) | | |
| | **5** | **Үзәктән җылыту** | | |
| 82 | 5.1 | Җылылыкны исәпкә алу төене урнаштыру (элеватор төене)* | компл. | 133208 |
| 83 | 5.2 | 20 мм диаметрлы баланслаучы клапан урнаштыру | 1 клапан | 2438 |
| 84 | 5.3 | Подвалдагы корыч торбаүткәргечләрне алмаштыру, җылытып | м | 2233 |
| 85 | 5.4 | Чардактагы җылыта торган корыч торбаүткәргечләрне алмаштыру | м | 1181 |
| 86 | 5.5 | Уку-укыту эшләре бүлегендә корычтан ясалган җылыту торбаүткәргечләрен чуен радиаторларга алмаштыру | м | 2084 |
| 87 | 5.6 | Торбаүткәргечләрдәге җылылык изоляциясен алмаштыру | м | 369 |
| 88 | 5.7 | Җылыта торган корыч торбаларны алмаштыру | м | 1009 |
| 89 | 5.8 | Чуен радиаторларны чуенга алмаштыру | секция | 622 |
| 90 | 5.9 | Чуен радиаторларны алюминийга алмаштыру | секция | 618 |
| | **6** | **Канализация** | | |
| 91 | 6.1 | Подвал өлешен алмаштырып, чуен торбаүткәргечләрне полиэтиленлыга алмаштыру | м | 1606 |
| 92 | 6.2 | Уку-укыту эшләре бүлегендә чуен торбаүткәргечләрне полиэтиленлыга алмаштыру | м | 1575 |
| 93 | 6.4 | Тышчасын торгызып, канализация кисәкләрен полиэтиленлы торбаларга алмаштыру | м | 5878 |
| 94 | 6.5 | Тышчасын торгызып, сырлы, арматура белән ясалган полиэтилен торбалардан ясалган канализация кисәкләрен | м | 9766 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | алмаштыру | | |
| 95 | 6.6 | Полиэтилен торбалардан ясалган су агыза торган эчке торбаларны ремонтлау (стеналарны ремонтлап, су агып төшә торган бүрәнкәләрне алмаштырып һ.б.) | м | 2390 |
| | 6.7 | **Санитар-техних җайланмаларны алмаштыру** | | |
| 96 | 6.7.1 | Бер бүлемтеккә юынгыч алмаштыру | 1 җайланма | 2348 |
| 97 | 6.7.2 | Ике бүлемтеккә юынгыч алмаштыру (туглагычы белән бергә хуҗалык өчен юу ваннасы) | 1 җайланма | 11763 |
| 98 | 6.7.3 | Кулъюгыч алмаштыру (кронштейннарда) | 1 җайланма | 1567 |
| 99 | 6.7.4 | Кулъюгыч алмаштыру (Тюльпан тибында) | 1 җайланма | 2168 |
| 100 | 6.7.5 | Баскыч алмаштыру | 1 җайланма | 1010 |
| 101 | 6.7.6 | Кечкенә багы белән бергә унитаз алмаштыру (Компакт тибында) | 1 җайланма | 4686 |
| 102 | 6.7.7 | Писсуар алмаштыру | 1 җайланма | 1632 |
| 103 | 6.7.8 | Биде алмаштыру | 1 җайланма | 3475 |
| 104 | 6.7.9 | Юдырып җибәрә торган кечкенә бакны алмаштыру | 1 җайланма | 1374 |
| 105 | 6.7.10 | Аскуйманы алмаштыру | 1 җайланма | 2363 |
| 106 | 6.7.11 | Сыгылмалы олауны алмаштыру | 1 җайланма | 252 |
| 107 | 6.7.12 | Сифон алмаштыру | 1 җайланма | 488 |
| 108 | 6.7.13 | Душ челтәре белән бергә туглагычны алмаштыру | 1 җайланма | 1987 |
| 109 | 6.7.14 | Душ челтәреннән башка гына туглагыч алмаштыру | 1 җайланма | 1381 |
| 110 | 6.7.15 | Инвалидлар өчен тоткычлар урнаштыру | 1 компл. | 4473 |
| | **7** | **Салкын суүткәргеч** | | |
| 111 | 7.1 | Салкын суны исәпкә алу төене урнаштыру* | компл. | 53394 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 112 | 7.2 | Подвалда корычтан ясалган салкын су торбаүткәргечен алмаштыру, җылытып | м | 1368 |
| 113 | 7.3 | Подвалда корычтан ясалган салкын су торбаүткәргечен полипропиленлыга (PN 20) алмаштыру, җылытып | м | 1585 |
| 114 | 7.4 | Янгынга каршы щитлар урнаштырып, корычтан ясалган янгын торбаүткәргечләрен алмаштыру | м | 3216 |
| 115 | 7.5 | Уку-укыту эшләре бүлегендә корычтан ясалган салкын су торбаүткәргечен полипропиленлыга (PN 20) алмаштыру | м | 1292 |
| | **8** | **Кайнар суүткәргеч** | | |
| 116 | 8.1 | Бойлерын алмаштырып, подвалдагы корыч торбаүткәргечләрне арматурадан ясалган полипропиленлыга PN 25 алмаштыру | м | 1784 |
| 117 | 8.2 | Бойлерын алмаштырмыйча гына, подвалдагы корыч торбаүткәргечләрне арматурадан ясалган полипропиленлыга PN 25 алмаштыру | м | 1669 |
| 118 | 8.3 | Уку-укыту эшләре бүлегендә корычтан ясалган торбаүткәргечне арматурадан ясалган полипропиленлыга PN 25 алмаштыру | м | 1213 |
| 119 | 8.4 | Бойлер алмаштыру* | 1 җайланма | 27407 |
| 120 | 8.5 | Сөлге киптергечләрне алмаштыру (күгәрми торган корычтан) | 1 җайланма | 2108 |
| 121 | 8.6 | Сөлге киптергечләрне алмаштыру (хромланган) | 1 җайланма | 1561 |
| 122 | 8.7 | Су җылыткычларны алмаштыру* | 1 җайланма | 29534 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **9** | **Электромонтажлау эшләре** | | |
| 123 | 9.1 | Подвалдагы электромонтажлау эшләре (ВРУ алмаштырып) | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 69 |
| 124 | 9.2 | Уку-укыту эшләре бүлегендә электромонтажлау эшләре (яктырткычларны һәм такталарны алмаштырып) | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 219 |
| 125 | 9.3 | Чардактагы электряктырткыч линияләрен алмаштыру | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 36 |
| 126 | 9.4 | Фасадтагы электряктырткыч линияләрен алмаштыру | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 34 |
| 127 | 9.5 | Яшеннән саклагыч урнаштыру | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 11 |
| 128 | 9.6 | Төтен бетерү һәм янгын сигнализациясе буенча автоматлаштырылган системаны (АППЗ) алмаштыру | мәктәпнең гомуми мәйданының кв. м | 371 |
| | **10** | **Җилләтү** | | |
| 129 | 10.1 | Юллыкларны, җилләтү шахталарын һәм җилләтү каналларын ремонтлау | гомуми мәйданның кв. м | 192 |
| 130 | 10.2 | Санитар узелларда һаваүткәргечләр, җилләткечләр, җилләтү рәшәткәләре урнаштыру | гомуми мәйданның кв. м | 15 |

Искәрмәләр: 1. Фасадларны ремонтлаганда стенаның тышка чыгып торган аскы өлешен ремонтлау эшләре исәпкә алынды;

бина тирәли фундаментны судан саклаучы авыш өслекне ремонтлау эшләрен 1.14 п.п. аерым исәпкә алырга кирәк;

1.15 п.п. бары тик күрсәтелгән эшләрне башкарган очракта гына исәпкә алына.

2. Түбәләрне ремонтлаганда эшләрнең тулы составы исәпкә алынды.

3. *Хакы проект буенча үзгәртелергә мөмкин.

4. 5.3 - 5.5 пунктларда эшләрнең тулы комплексы исәпкә алынды;

5.6-5.9 п.п. бары тик күрсәтелгән эш төрләре башкарылган очракта гына кулланыла.